| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| РЕШЕНИЕ<br>25.04.2024 | Зеленодольск<br>шәһәре | КАРАР<br>№ 389 |

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында «Зеленодольск муниципаль районы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе А. Ю. Алексахинаның мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышканнан соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында нигезләмәне әлеге карарга кушымтада каралганча расларга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2019 елның 30 декабрендәге «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәткә идарә итү һәм эш итү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 474 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы ,
Советы рәисе М. П. Афанасьев

Зеленодольск муниципаль районы Советының
«25» апрелендәге 389 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәт белән идарә итү
һәм эш итү тәртибе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә түбәндәгеләр нигезендә эшләнгән:
- Россия Федерациясе Конституциясе,
- Россия Федерациясе Граждан Кодексы,
- 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 131-ФЗ номерлы Закон),
- 2002 елның 14 ноябрендәге «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 161-ФЗ номерлы Федераль закон,
- 2015 елның 13 июлендәге «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 218-ФЗ номерлы Федераль закон
- 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 178-ФЗ номерлы Закон);
- РФ Хөкүмәтенең 2012 елның 27 августындагы «Дәүләт яисә муниципаль мөлкәтне электрон рәвештә сатуны оештыру һәм уздыру турында» 860 номерлы карары . 860 номерлы карары
- башка федераль законнар ,
- Татарстан Республикасы Конституциясе,
- 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы,
- Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба - район Уставы) белән.

1.2. Нигезләмә Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибен (алга таба - Нигезләмә), мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендә хокукларны һәм бурычларны гамәлгә ашыруда Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен билгели.

1.3. Әлеге Нигезләмә белән җайга салынмаган милек мөнәсәбәтләре, шул исәптән җирле бюджет акчалары, бюджеттан тыш фондлар, торак фонды, җир һәм башка табигый ресурслар белән идарә һәм эш итү үзенчәлекләре, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив актлары (алга таба – районның җирле үзидарә органнары) тарафыннан җайга салына.

1.4. Муниципаль милек белән идарә һәм эш итүнең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1)муниципаль мөлкәт белән нәтиҗәле идарә итү нигезендә Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәрен арттыру (алга таба - район бюджеты) ;

2)муниципаль мөлкәт структурасын оптимальләштерү;

3)Зеленодольск муниципаль районы икътисадына инвестицияләр җәлеп итү өчен инструмент буларак муниципаль мөлкәтне куллану;

4)муниципаль мөлкәтне файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү.

1.5. Муниципаль мөлкәткә Зеленодольск муниципаль районы территориясендә һәм аннан читтә урнашкан, дәүләт милкен чикләү нәтиҗәсендә муниципаль берәмлеккә тапшырылган яки гражданлык законнары нигезендә билгеләнгән башка нигездә сатып алынган барлык объектлар керә.

1.6. Муниципаль мөлкәт Зеленодольск муниципаль районының муниципаль казнасыннан (алга таба - Район казнасы) һәм муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару, оператив идарә итү хокукында һәм муниципаль учреждениеләргә оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәттән тора.

1.7. Зеленодольск муниципаль районы (алга таба - район) милкендә түбәндәгеләр булырга мөмкин:

1) районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

2) федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары белән билгеләнгән очракларда җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук 131-ФЗ номерлы Законның 15 статьясының 4 өлешендә каралган тәртиптә җирле үзидарә органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт;

3) Зеленодольск муниципаль районы Советы (алга таба - район Советы)җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә районның җирле үзидарә органнары һәм район җирле үзидарәсенең вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

4) җирле үзидарә органнарына федераль законнар белән хокук бирелгән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә карармаган мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле мөлкәт;

5) 131-ФЗ номерлы законның 14 статьясының 3 һәм 4 өлешләренә ярашлы рәвештә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук 131-ФЗ номерлы Законның 17 статьясының 1 һәм 1.1 өлешләренә ярашлы рәвештә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт.

1.8. Район казнасын район бюджеты акчалары һәм муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә беркетелмәгән башка муниципаль мөлкәт тәшкил итә.

Район казнасы мөлкәте юридик һәм физик затларга хуҗалык карамагына, оператив идарәгә, арендага, түләүсез файдалануга, ышаныч идарәсенә, залогка (ипотекага) тапшырылырга , гамәлдәге законнарда һәм әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә тартып алынырга мөмкин.

Казна мөлкәте гамәлдәге законнарда билгеләнгән очракларда Зеленодольск муниципаль районы йөкләмәләре буенча түләттерү объекты булырга мөмкин

## 2. Муниципаль милектә булган мөлкәткә карата милекченең хокукый вәкаләтләрен тормышка ашыру

2.1. «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге үзенә караган мөлкәтнең хуҗасы булып тора.

2.2. Зеленодольск муниципаль районы исеменнән районның муниципаль милке составына керүче мөлкәткә карата милекче хокукларын район Уставы, шушы Нигезләмә, әлеге органнарның статусын билгели торган башка актлар белән урнаштырылган районның җирле үзидарә органнары, үз компетенцияләре кысаларында, гамәлгә ашыра.

2.3. Районның җирле үзидарә органнары муниципаль мөлкәтне физик һәм юридик затларга, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына вакытлыча яки даими файдалануга тапшырырга, федераль законнар нигезендә тартып алырга, башка килешүләр төзергә хокуклы.

2.4. Район Советы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

- район милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибен билгеләү;

- муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрне булдыру, үзгәртеп кору һәм бетерү турында, шулай ук муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәт күрсәтүләренә , эшләрен башкаругa тарифлар урнаштыру турында карарлар кабул итүтәртибен билгеләү , Федераль законнарда каралган очраклардан тыш;

- хосусыйлаштыру яки читләштерү өчен тәкъдим ителә торган Зеленодольск муниципаль районының күчемсез милек объектлары исемлеген раслау;

- план чорына муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) раслау.

- муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планының (программасының) үтәлеше турындагы хисапны раслау;

- муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

- районның җирле үзидарә органнары һәм районның җирле үзидарәсе вазыйфаи затлары тарафыннан район милкендәге мөлкәткә ия булу, файдалану һәм аның белән эш итү мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында һәм районның муниципаль хокукый актларында билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2.5. Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы (алга таба - район Башлыгы) Зеленодольск муниципаль районы исеменнән:

- муниципаль мөлкәт белән идарә итү өлкәсендә район сәясәтенең төп юнәлешләрен билгели;

- үз компетенциясе кысаларында муниципаль мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү буенча карарлар кабул итә;

- Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм район Уставы нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2.6. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә муниципаль мөлкәт белән идарә итү өлкәсендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – район Башкарма комитеты) компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

- Зеленодольск шәһәренең муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итү, районның муниципаль милке объектларын булдыру, сатып алу, куллану, эш итү һәм арендалау мәсьәләләрен хәл итү;

- район Советы карары белән билгеләнгән очракларда район Советына районның муниципаль мөлкәтен читләштерү, шул исәптән аны хосусыйлаштыру турында тәкъдимнәр әзерләү һәм аларны килештерүгә (раслауга) чыгару;

- муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турында карар кабул итү;

- муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзү, аларның максатларын, эшчәнлек шартларын һәм тәртибен билгеләү, аларның уставларын раслау, муниципаль казна учреждениеләрен финанслауны тәэмин итү,

муниципаль учреждениеләрне һәм предприятиеләрне үзгәртеп кору һәм бетерү мәсьәләләрен хәл итү, аларның җитәкчеләрен контракт нигезендә билгеләү һәм биләгән вазифаларыннан азат итү;

- муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, оешмалар белән районның икътисадый һәм социаль үсешендә хезмәттәшлек турында шартнамәләр төзү; район территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милек рәвешләрендәге предприятиеләр төзүгә ярдәм итү;

- Зеленодольск муниципаль районының хезмәт күрсәтелә торган административ участогында эшләү өчен участок полициясе вәкаләтлесе вазыйфасын биләүче хезмәткәргә урын бирү.

## 3. Муниципаль мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәве

3.1. Муниципаль милек хокукы, хуҗалык алып бару хокукы һәм районның муниципаль күчемсез милек объектларына оператив идарә итү хокукы законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынырга тиеш  һәм алар шушы теркәлүне узганнан соң барлыкка килә.

Гамәлдәге законнарда билгеләнгән очракларда муниципаль милек хокукын дәүләт теркәвенә алу белән беррәттән, аңа  хокукны чикләүләр (йөкләмәләр) дә дәүләт теркәвен үтәргә тиеш.

3.2. Хокукларны һәм чикләүләрне (йөкләтүләрне) дәүләт теркәвенә алу яңа төзелгән яисә сатып алынган мөлкәткә дә, шулай ук элек Зеленодольск муниципаль районының муниципаль милек реестрында исәпкә алынган мөлкәткә дә (алга таба — Реестр) гамәлгә ашырыла.

3.3. Күчемсез мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәвенә алу өчен документлар рәсмиләштерүне һәм тапшыруны түбәндәгеләр гамәлгә ашыра:

1) район муниципаль казнасының күчемсез мөлкәтенә муниципаль милек хокукы-район Башкарма комитеты, ә ышанычнамәсе тиешенчә рәсмиләштерелгән очракта-Вәкаләтле орган;

2) хуҗалык алып бару хокуклары һәм оператив идарә хокуклары-хокукка ия булучылар;

3) арендалау хокуклары - арендаторлар; ышанычлы идарә итү - район Башкарма комитеты , ә ышанычнамәсе тиешенчә рәсмиләштерелгән очракта-Вәкаләтле орган;

4)милек хокукының (ипотека, сервитут)чикләүләре (йөкләтүләре) - чикләү файдасы билгеләнә торган зат;

5) муниципаль мөлкәтне читләштергәндә милек хокуклары - район башкарма комитеты , ә ышанычнамәсе тиешенчә рәсмиләштерелгән очракта-Вәкаләтле орган;

3.4. Техник паспортлаштыруга, район казнасының күчемсез милек объектларына карата дәүләт кадастр исәбенә кую чыгымнары район бюджетының чыгым өлешендә карала һәм расланган сметага ярашлы рәвештә район бюджетыннан финанслана.

## 4. Муниципаль мөлкәтне исәпкә алу.

4.1. Зеленодольск муниципаль районы милкендә булган муниципаль мөлкәт (җирле бюджет һәм бюджеттан тыш фондлардан тыш), шул исәптән түбәндәгеләр Реестрда мәҗбүри исәпкә алынырга тиеш:

- муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән мөлкәт;

- муниципаль учреждениеләргә оператив идарә хокукында  беркетелгән мөлкәт;

- район милкендә булган акционер җәмгыятьләрнең акцияләре;
- хуҗалык җәмгыятьләренең, ширкәтләренең устав (җыелма) капиталына район өлешләре (кертемнәре);
- район казнасы мөлкәте.

4.2. Мөлкәт муниципаль казнага түбәндәге очракларда керә:
- дәүләт (федераль һәм Россия Федерациясе субъекты) милкенә һәм муниципаль милеккә чикләү турындагы законнарда каралган тәртиптә муниципаль милеккә тапшырганда;
- әгәр мөлкәт җирле бюджет акчалары хисабына яңадан төзелгән яки турыдан- туры муниципаль милеккә сатып алынган булса;
- юридик һәм физик затлар тарафыннан муниципаль милеккә түләүсез тапшырганда;
- законлы нигездә муниципаль унитар предприятиеләрне хуҗалык алып барудан төшереп калдырганда һәм муниципаль учреждениеләрне оператив идарә итүне гамәлдән чыгарганда;
- әгәр мөлкәт муниципаль унитар предприятиеләр һәм муниципаль учреждениеләрне бетергәннән соң калган булса;
- законга каршы килми торган башка нигезләр буенча муниципаль милеккә кергәндә.

4.4. Казна мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү тәртибе Зеленодольск муниципаль районы казнасының мөлкәте турындагы нигезләмә белән билгеләнә.

## 5. Муниципаль унитар предприятиеләр һәм муниципаль учреждениеләр тарафыннан хуҗалык алып бару һәм оператив идарә итү хокукын гамәлгә ашыру

5.1. Муниципаль унитар предприятиеләргә һәм муниципаль учреждениеләргә үзләренең устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле булган муниципаль мөлкәт, шулай ук гамәлдәге закон нигезендә эшчәнлек барышында сатып алынган мөлкәт беркетелә.

5.2. Муниципаль мөлкәт муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә түбәндәге очракларда беркетелә:
- муниципаль предприятиеләр һәм муниципаль учреждениеләр төзегәндә;
- хуҗалык эшчәнлеге барышында әлеге затларның мөрәҗәгате буенча (шул исәптән, мөлкәтнең предприятиегә яки учреждениегә балансы буенча);
- муниципаль мөлкәтне предприятиеләр һәм учреждениеләр арасында яңадан бүлгәндә (балансстан балplanска тапшыру);
- муниципаль унитар предприятиеләрне һәм муниципаль учреждениеләрне үзгәртеп корганда;

- алар үз эшчәнлекләреннән, шул исәптән рөхсәт ителгән эшмәкәрлек эшчәнлегеннән (муниципаль учреждениеләр, предприятиеләр өчен) керемнәр хисабына мөлкәт сатып алганда.

5.3. Район Башкарма комитеты карары буенча мөлкәт муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында, муниципаль учреждениеләргә оператив идарә хокукында беркетелә.

5.4. Мөлкәтне беркетү турындагы мәсьәләне хәл итү өчен предприятие яки учреждениедән түбәндәгеләр таләп ителергә мөмкин:

- предприятие яки учреждение карамагында булган мөлкәтнең инвентаризация исемлеге;

- мөлкәт сатып алуга накладнойлар;

- мөлкәт сатып алу буенча башка документлар.

5.5. Предприятие яки учреждение төзегәндә (үзгәртеп корганда) мөлкәтне беркетү өчен кирәкле документлар булып түбәндәгеләр тора:

- предприятие яки учреждениене теркәү турында таныклык;

- предприятие яки учреждение уставы ;

- бүленеш балансы яки тапшыру акты;

расланган форма буенча типларга (биналар, корылмалар, машиналар һәм җиһазлар, транспорт чаралары, инструментлар, җитештерү һәм хуҗалык инвентарьлары һәм башка төп чараларга) бүленгән төп чараларның расшифровкасы;

- күчемсез мөлкәт объектларына техник документлар (паспортлар, өземтәләр, белешмәләр, актлар).

5.6 Муниципаль мөлкәт район Башкарма комитеты карары буенча учреждениеләр арасында(баланстан балanска тапшыру), аларның нигезле тәкъдимнәре нигезендә, яңадан бүленергә мөмкин.

5.7. Муниципаль мөлкәтне тапшыру, тиешле карар кабул ителгәннән соң, бер ай эчендә, бухгалтерлык исәбенә алынган форма буенча кабул итү-тапшыру акты белән рәсмиләштерелә.

5.8. Муниципаль предприятиеләр һәм муниципаль учреждениеләр гамәлдәге законнарда, район Башкарма комитетының хокукый актларында һәм оештыру документларында билгеләнгән хокуклылыгы чикләрендә хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында үзләренә беркетелгән муниципаль мөлкәткә ия булалар, аннан файдаланалар һәм алар белән эш итәләр.

5.9. Күчемсез мөлкәткә предприятиенең хуҗалык алып бару хокукы яки учреждениенең идарә итү хокукы мондый хокукны дәүләт теркәвенә алган мизгелдән барлыкка килә.

Хуҗалык алып бару һәм оператив идарә итү хокукын дәүләт теркәвенә алу бурычы, объектларны паспортлаштыруны гамәлгә ашыруны да кертеп, предприятие һәм учреждениегә йөкләнә.

5.10. Предприятиедә хуҗалык алып баруның һәм учреждениедә оператив идарә итүнең хокукы түбәндәге күчемле мөлкәткә барлыкка килә:

- мөлкәтне кабул итү-тапшыру актына кул куелганнан соң беркетелгән мөлкәткә;

– предприятие яки учреждение тарафыннан мөстәкыйль сатып алынган мөлкәткә-мөлкәт предприятиенең яки учреждениенең үз балансына куелганнан соң.

5.11. Аерым торучы күчемсез милек объектларын хуҗалык алып баруга яки оператив идарәгә тапшырганда предприятие һәм учреждение җир кишәрлегенә хокукларын рәсмиләштерү буенча чаралар башкара. Җир кишәрлегенә хокукларны дәүләт теркәвенә алу һәм җир төзелеше эшен формалаштыру бурычы предприятие һәм учреждениегә йөкләнә.

5.12. Предприятие һәм учреждениеләрнең хуҗалык алып бару һәм оператив идарә итү хокукы туктатыла:

- күчемле мөлкәт буенча - район Башкарма комитеты карары буенча башка юридик затка тапшырганда яки мөлкәтне кире кайтарганда мөлкәтне кабул итү-тапшыру актына кул куйганнан соң;

- күчемсез мөлкәт буенча-Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукын туктату турында язу кертелгән моменттан.

5.13. Хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукын туктату турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына язу кертү буенча чаралар үткәрү бурычы предприятие һәм учреждениегә йөкләнә.

5.14. Муниципаль предприятие мөлкәте милекчесе мондый предприятие карамагындагы муниципаль мөлкәтне файдаланудан кергән табыш өлешен алырга хокуклы.

Район бюджетына күчерелергә тиешле муниципаль унитар предприятиеләрнең табыш өлеше күләме, район Башкарма комитеты карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең чиста табышының район бюджетына күчерелергә тиешле өлешен билгеләү тәртибе нигезендә тормышка ашырыла.

## 6. Предприятиеләргә хуҗалык алып бару һәм учреждениеләргә оператив идарә хокукында беркетелгән мөлкәтне исәптән төшерү тәртибе

6.1. Предприятиеләргә хуҗалык алып бару һәм учреждениеләргә оператив идарә итү хокукында беркетелгән төп чараларны исәптән төшерү түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

- мораль һәм физик яктан тузу;
- аварияләрдә, табигый бәла-казалар һәм башка гадәттән тыш хәлләрдә ликвидацияләү;
- вәкаләтле органнар тарафыннан билгеләнгән муниципаль мөлкәтне урлау, янгын;
- реконструкция эшләрен башкарганда өлешчә бетерү.

6.2. Муниципаль мөлкәтне исәптән чыгару тәртибе район Советы тарафыннан раслана торган Нигезләмә белән билгеләнә.

## 7. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары

7.1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру астында муниципаль милкендә булган мөлкәтне физик һәм (яки) юридик затлар милкенә түләүле рәвештә читләштерү таныла.

7.2. Хосусыйлаштыру турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары һәм әлеге Нигезләмә нигезендә муниципаль милек объектларын хосусыйлаштыру гамәлгә ашырыла.

7.3. Хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) 2001 елның 21 декабрендәге "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" гы 178-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 декабрендәге 806 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планнарын (программаларын) эшләү кагыйдәләре нигезендә башкарыла.

7.4. Җирле үзидарә органнары, муниципаль унитар предприятиеләр, шулай ук акцияләре, устав капиталындагы өлешләре муниципаль милектә булган җаваплылыгы чикләнгән акционер җәмгыятьләре һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр, башка юридик затлар һәм гражданнар муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында үз тәкъдимнәрен район Башкарма комитетына җибәрергә хокуклы.

7.5. Хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) түбәндәгеләрне үз эченә ала: хосусыйлаштыру план чорында планлаштырыла торган муниципаль мөлкәтнең икътисадый эшчәнлек төрләре буенча төркемләшкән исемлеге(унитар предприятиеләр, муниципаль милектәге акционер җәмгыятьләрнең акцияләре һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрнең устав капиталларындагы өлешләре, район казнасын тәшкил итүче башка мөлкәт),тиешле мөлкәтнең характеристикасын, хосусыйлаштыруның фаразланган срокларын һәм Зеленодольск муниципаль районы бюджетына кертемнәр күләмен фаразлауны күрсәтеп;

7.6. Район Советы:

1) Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) раслый;

2) муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүне раслый;

3) муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планының (программасының) үтәлеше турында хисапны раслый;

4) муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны контрольдә тотуны гамәлгә ашыра.

7.8. Район Башкарма комитеты:

1) чираттагы финанс елы башланганчы сигез айдан да соңга калмыйча, муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында тәкъдимнәрне район Советына тапшыра;

2) план чорына муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) проектын эшли(Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 декабрендәге 806 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планнарын (программаларын) эшләү кагыйдәләре нигезендә) һәм план чоры башланганчы, 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, район Советына раслау өчен тәкъдим итә;

3) муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү проектын эшли;

4) муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразланган планын (программасын) район Советы тарафыннан расланган көннән алып 10 көн эчендә «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Зеленодольск муниципаль районының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль закон белән билгеләнгән таләпләр нигезендә сатулар үткәрү турында мәгълүматны бастыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында (http://www.torgi.gov.ru) урнаштыра ;

5) муниципаль мөлкәтне сатучы булып тора;

6) 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" гы Федераль законның 14 статьясы нигезендә хосусыйлаштыру шартлары турында карар кабул итә.

7) хосусыйлаштыруны планлаштырылган чорга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) кертмичә генә башкарыла торган муниципаль мөлкәт исемлеген формалаштыру һәм раслау , шулай ук күрсәтелгән исемлеккә үзгәрешләр кертү тәртибен билгели;

8) хосусыйлаштыруны планлаштырылган чорга муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) кертмичә башкарыла торган муниципаль мөлкәт исемлеген раслаучы муниципаль башкарма хакимият органы билгели;

9) ел саен, 1 февральдән дә соңга калмыйча, район Советына әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтадагы форма буенча узган ел өчен муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турында хисап әзерли һәм тапшыра;

10) район Советына тапшыру белән бер үк вакытта узган ел өчен муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турында хисап "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), сатулар үткәрү турында мәгълүматны бастыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында(http://www.torgi.gov.ru) урнаштыра.

7.9. Район Башкарма комитеты муниципаль мөлкәтне сату өчен билгеләнгән тәртиптә махсуслаштырылган оешмаларны җәлеп итәргә хокуклы.

8. Муниципаль мөлкәтне арендага бирү.

8.1. Зеленодольск муниципаль районы муниципаль мөлкәтен арендага бирүчеләр булып түбәндәгеләр тора:

1) Казна мөлкәтенә карата «ЗМР җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» МУ ;

2) Хуҗалык алып бару хокукында беркетелгән мөлкәткә карата Зеленодольск муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре;

3) оператив идарә хокукында беркетелгән мөлкәткә карата Зеленодольск муниципаль районының муниципаль казна предприятиеләре һәм муниципаль учреждениеләре;

8.2. Муниципаль мөлкәтне арендага алучылар юридик затлар һәм физик затлар булырга мөмкин.

8.3. Арендага җир кишәрлекләре, күчемле һәм күчемсез мөлкәт (биналар, корылмалар, биналар), бердәм мөлкәт комплекслары тапшырылырга мөмкин.

8.4. Җир кишәрлекләрен арендага бирү җир турындагы законнар белән билгеләнә.

8.5. Зеленодольск муниципаль районының муниципаль мөлкәтен тапшыру тәртибе Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясы һәм район Советы тарафыннанраслана торган Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

8.6. Аренда түләве «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнә.

9. Муниципаль милек объектларын түләүсез файдалануга тапшыру.

9.1. Муниципаль милек объектлары гражданлык законнары һәм «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә түләүсез файдалану шартнамәләре нигезендә түләүсез файдалануга тапшырылырга мөмкин.

9.2. Муниципаль милек объектларын түләүсез файдалануга тапшыру турындагы карарны район Башкарма комитеты кабул итә.

9.3. Түләүсез файдалану шартнамәсе (ссудалар шартнамәсе) буенча ссуда бирүче булып «ЗМР мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ тора.

9.4. Муниципаль мөлкәтне ссуда алучы файдаланыла торган мөлкәтне тиешле хәлдә тотарга, аны ссудалар шартнамәсе шартлары нигезендә агымдагы, капиталь ремонтларга һәм, гомуми белем бирү учреждениеләрендә кайнар ризык белән мәктәп туклануын оештыру буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмаларга тапшырыла торган мөлкәттән тыш, коммуналь хезмәтләр өчен түләргә тиеш. Капиталь ремонт үткәрүнең кирәклеге һәм сроклары ссуда алучы белән мәҗбүри рәвештә килештерелергә тиеш.

9.5. Муниципаль мөлкәт объектлары почта элемтәсе бүлекчәләрен урнаштыру өчен «Россия Почтасы» АҖнең түләүсез файдалану шартнамәләре нигезендә түләүсез файдалануга тапшырылырга мөмкин.

## 10. Муниципаль мөлкәтне ышанычлы идарәгә тапшыру

10.1. Муниципаль мөлкәт «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге мәнфәгатьләрендә ышанычлы идарәгә тапшырылырга мөмкин.

10.2. Предприятиеләр һәм башка мөлкәт комплекслары, күчемсез мөлкәткә караган аерым объектлар, кыйммәтле кәгазьләр, документлар булмаган кыйммәтле кәгазьләр белән таныкланган хокуклар, махсус хокуклар һәм башка мөлкәт ышанычлы идарә итү объектлары булырга мөмкин.

10.3. Муниципаль унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан хуҗалык алып бару яки оператив идарә итү хокукында районның җирле үзидарә органнарына беркетелгән мөлкәтне ышаныч идарәсенә тапшыру рөхсәт ителми.

10.4. Ышаныч идарәсен гамәлгә куючы булып торган районның Башкарма комитеты тарафыннан ышаныч идарәсе шартнамәсе төзелә.

10.5. Муниципаль мөлкәт объектларын ышаныч идарәсенә тапшыру шартлары, мөмкин булган бүләкләү күләме, шулай ук кирәкле чыгымнарны каплау гамәлдәге законнар нигезендә район Башкарма комитетының хокукый акты белән билгеләнә.

10.6. Шартнамә нигезендә ышанычлы идарә итү шартларының берсе буларак, билгеле бер вакыт узганнан соң, ышаныч белән идарә итүче вазифасына кертелгән ирешелгән нәтиҗә каралырга тиеш.

10.7. Мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәсендә түбәндәгеләр күрсәтелгән булырга тиеш:

ышаныч идарәсенә тапшырыла торган мөлкәт составы;

ышанычлы идарәне гамәлгә куючы исеме;

бүләкләү өчен түләү шартнамәдә каралган булса, идарәчене бүләкләү күләме һәм формасы;

шартнамәнең гамәлдә булу срогы.

Шартнамә нигезендә ышанычлы идарә итү шартларының берсе буларак, билгеле бер вакыт узганнан соң, ышаныч белән идарә итүче вазифасына кертелгән ирешелгән нәтиҗә каралырга тиеш.

10.8. Мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәсе биш елдан да артмаган срокка төзелә. Ышанычлы идарәгә тапшырыла торган аерым төр мөлкәт өчен гамәлдәге законнар белән шартнамә төзелергә мөмкин булган башка чик сроклар билгеләнергә мөмкин.

Шартнамәнең гамәлдә булу вакыты тәмамлангач, аны туктату турында бер якның гаризасы булмаса, ул шартнамәдә каралган шул ук срокка һәм шартларда озайтылган дип санала.

10.9. Ышаныч идарәсенә тапшырылган мөлкәт идарәне оештыручының башка мөлкәтеннән, шулай ук ышаныч идарәчесенең мөлкәтеннән аерып алына. Бу мөлкәт ышанычлы идарәчедә аерым баланста чагылыш таба һәм аның буенча мөстәкыйль исәп-хисап алып барыла. Ышанычлы идарә белән бәйле эшчәнлек буенча исәп-хисап ясау өчен аерым банк счеты ачыла.

11. Муниципаль мөлкәтне залогка тапшыру.

11.1. Муниципаль мөлкәт залогы белән бәйле гамәлләр Россия Федерациясе граждан законнары белән җайга салына. Район казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтнең нигезе түбәндәгеләрне тәэмин итү өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин:

- районның йөкләмәләрен;

- Зеленодольск муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре, үтәлеше белән Зеленодольск муниципаль районы кызыксына торган устав капиталында Зеленодольск муниципаль районының өлеше булган хуҗалык җәмгыятьләре йөкләмәләрен.

11.2. Залогның предметы булып теләсә кайсы муниципаль мөлкәт, шул исәптән әйберләр һәм мөлкәт хокуклары (таләпләр) булырга мөмкин, түбәндәге мөлкәттән тыш:

- гамәлдәге законнар нигезендә әйләнештән алынган әйберләр;

- Зеленодольск муниципаль районының мәдәни мирасын тәшкил итүче муниципаль музейлар, архивлар, китапханәләр, мәдәният йортлары һәм сарайлары, стадионнар, спорт клублары, техник һәм фәнни иҗат йортлары, балалар иҗат йортлары;

- хосусыйлаштыру тыелган;

- натурада аларның максатчан билгеләнешен үзгәртмичә генә бүленүе мөмкин булмаган күчемсез объектларның бер өлеше (өлешләре);

- башка затка хокукларны бирү федераль закон белән тыелган.

Мөлкәтнең аерым төрләре залогы федераль закон белән тыелырга яки чикләнергә мөмкин.

11.3. Күчемсез муниципаль мөлкәт объектының залогы һәм аны залогка тапшыру шартлары турындагы карар район Советы тарафыннан федераль законнар нигезендә кабул ителә.

12. Зеленодольск муниципаль районының муниципаль милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләренең (ширкәтләренең ) акцияләре, устав (җыелма) капиталларындагы өлешләре белән идарә итү

12.1. Муниципаль милкендә булган хуҗалык җәмгыятьләренең (ширкәтләренең )акцияләре, устав (җыелма) капиталларындагы өлешләре белән идарә итү район Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

12.2. Хуҗалык җәмгыятьләре белән идарә итүдә катнашу муниципаль вәкилләр аша башкарыла, аларның кандидатуралары район Башкарма комитеты карары белән раслана.

12.3. Муниципаль предприятиеләрне хосусыйлаштыру тәртибендә оештырылган акционер җәмгыятьләрен гамәлгә куючы-район Башкарма комитеты.

12.4. Хуҗалык җәмгыятьләрендә Зеленодольск муниципаль районы катнашуыннан алынган керемнәр (дивидендлар) тулы күләмдә район бюджетына җибәрелә.

## 13. Муниципаль мөлкәтне федераль милеккә һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкенә һәм башка муниципаль берәмлекләр милкенә тапшыру

13.1. Районның муниципаль мөлкәтен федераль милеккә һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкенә һәм башка муниципаль берәмлекләр милкенә тапшыру дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына беркетелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен дәүләт хакимиятенең федераль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләрне аерганда, шулай ук законнарда каралган башка очракларда гамәлгә ашырыла.

13.2. Районының муниципаль мөлкәтен федераль милеккә, Татарстан Республикасы дәүләт милкенә һәм башка муниципаль берәмлекләр милкенә тапшыру турында карар район Советы тарафыннан кабул ителә.

13.3. Районның муниципаль мөлкәтен федераль милеккә һәм Татарстан Республикасы дәүләт милкенә һәм башка муниципаль берәмлекләр милкенә тапшыру дәүләт хакимиятенең федераль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, районның җирле үзидарә органнары һәм муниципаль берәмлекләр инициативасы буенча башкарыла.

## 14. Муниципаль милекне кулланудан керемнәр

14.1. Муниципаль милектәге мөлкәтне файдаланудан алынган керемнәргә түбәндәгеләр керә:

- район казнасының муниципаль мөлкәтен арендага тапшырудан алына торган акчалар;

- «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә караган акцияләр (өлешләр) буенча хуҗалык җәмгыятьләренең устав (җыелма) капиталларындагы керемнәр;

-салым түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрдән соң калган муниципаль унитар предприятиеләр табышының бер өлеше;

- Зеленодольск муниципаль районы казнасының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштырудан керемнәр;

- Зеленодольск муниципаль районы казнасының муниципаль мөлкәтен файдаланудан Россия Федерациясе законнарында каралган башка керемнәр.

14.2. Муниципаль милектән файдаланудан керемнәр керемнәрнең салым булмаган төрләренә карый һәм район бюджетына күчерелә.

## 15. Муниципаль милек объектларын куллануны контрольдә тоту

15.1. Муниципаль мөлкәтне куллануның нәтиҗәлелеген арттыру, аны рациональ булмаган куллану очракларын билгеләү һәм билгеләнгән максат буенча куллану максатларында муниципаль мөлкәтне куллануны контрольдә тоту гамәлгә ашырыла.

15.2. Контрольне федераль законнар нигезендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга хокуклы булган орган (алга таба - Вәкаләтле орган) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

15.3. Вәкаләтле орган муниципаль унитар предприятиеләр һәм муниципаль учреждениеләр, шулай ук муниципаль мөлкәтнең билгеләнеше буенча файдалануын һәм саклануын контрольдә тоту өлешендә башка затлар эшчәнлеген документаль һәм башка тикшерүләр билгеләргә һәм үткәрергә хокуклы.

15.4. Муниципаль унитар предприятиеләр һәм муниципаль учреждениеләр, башка затлар җитәкчеләре муниципаль мөлкәт белән эш итү барышында закон бозу фактларын ачыклаганда кирәкле документлар һәм белешмәләр тапшырырга, шулай ук ачыкланган бозуларны Вәкаләтле орган күрсәткән срокларда бетерергә тиеш.

1 нче кушымта

Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) үтәү турында хисап ______________________ елларга

2023 елда хосусыйлаштырылган объектлар исемлеге

| № т/б | Мөлкәтнең исеме, мәйданы, адресы | Хосусыйлаштыру ысулы | Сатулар уздыру датасы | Башлангыч тәкъдимнең бәясе - базар бәясе (НДС белән), сум. | Сату-алу шартнамәсе буенча сумма(НДС белән), сум. |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | |
| 2 | | | | | |
| 3 | | | | | |
| 4 | | | | | |

Гамәлгә ашырылмаган объектлар исемлеге

| № т/б | Мөлкәтнең исеме, мәйданы, адресы | Бәяне күтәрү буенча аукцион турында хәбәр | Гавами тәкъдим юлы белән сату турында хәбәр | Башлангыч тәкъдимнең бәясе - базар бәясе (НДС белән), сум. | Сатылмыйча калуның сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |